# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге составына керүче Урман Асты Шонталасы авылы

10ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге составына керүче Урман Асты Шонталасы торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1.2021 елда Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм төзекләндерү;

- торак пунктта юллар төзекләндерү өчен материал сатып алу;
- бензогенератор сатып алу;
- чүп савытлары сатып алу һәм мәйданчыгын карап тоту;
- МТЗ -82.1 тракторына ягулык-майлау материаллары, автозапчастьләр сатып алу һәм трактор йөртүчегә хезмәт хакы түләү;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, су суырткыч сатып алу;
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту кышын һәм җәен (кардан чистарту һәм үләннәр чабу);

-сугыш ветераннарының һәйкәлен төзекләндерү(стелла сатып алу һәм аны урнаштыру)

- җирләү урыннарын төзекләндерү ( рәшәткә өчен кирәк-ярак сатып алу).

3.Әлеге карарны Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы бинасының мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин